ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.11.2021 Казан ш. № 387-93/кс-2021

«Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте өчен техник суга (әйләнешле су белән тәэмин итү) һәм ташландык су (сәнәгый һәм явым-төшемнән агып җыелган суларын) агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 04.12.2020 №353-159/кс-2020 карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2022-2025 елларга техник суга (әйләнешле су белән тәэмин итү), ташландык суларны (сәнәгый һәм явым-төшемнән агып җыелган суларны) агызуга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2025 елларга «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте өчен техник суга (әйләнешле су белән тәэмин итү) һәм ташландык су (сәнәгый һәм явым-төшемнән агып җыелган суларын) агызуга арифлар билгеләү турында» 04.12.2020 № 353-159/кс-2020 карарының 1 нче кушымтасына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
04.12.2020 № 353-159/кс-2020 карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
26.11.2021 № 387-93/кс-2021
карары редакциясендә) 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Казаньоргсинтез» ГАҖ өчен техник суга (әйләнештәге су белән тәэмин итү) һәм ташландык суларны (сәнәгый һәм явым-төшемнән агып җыелган сулары) агызуга 2021-2025 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Техник суга (әйләнешле су белән тәэмин итү) тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Ташландык суларны агызуга тариф (сәнәгый һәм явым-төшем агынты сулары) (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | |
| 1 | «Казаньоргсинтез» ГАҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 0,98 | 10,98 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1,14 | 11,67 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1,08 | 11,40 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1,08 | 11,40 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 1,08 | 11,40 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1,13 | 11,97 |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 1,13 | 11,97 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 1,20 | 12,00 |
| | | 01.01.25 башлап | 1,20 | 12,00 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 30.06.25 кадәр | | |
| | | 01.07.25 башлап<br>31.12.2025 кадәр | 1,20 | 12,59 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге